**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында гражданнар җыены карары**

2025елның 29 ноябре

№ 2

**Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары нигезендә, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы белән, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 елның 22 ноябрендәге 909 номерлы карары белән расланган (25.11.2024 №1049 редакциясендә) Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларына гражданнарның үзара салым акчаларын җәлеп итеп гамәлгә ашырыла торган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибенең 2 пункты белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы «Куакбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 24.1 маддәсе белән, Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пункты гражданнар җыены КАРАР БИРДЕ:

1. 2026 елда Лениногорск муниципаль районы Куакбаш авыл җирлегенең Куакбаш торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге бүлектә белем алучы студентлардан; Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарыннан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; Россия Федерациясе Кораллы көчләренә контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарыннан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан; махсус хәрби операция барышында һәлак булган МХОда катнашучыларның гаилә әгъзаларыннан тыш, 1000,00 (Бер мең) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:
1)торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Куакбаш авылында Совет, Ленин, М. Җәлил, һ. Такташ,К. Маркс, Маяковский, Тукай, Сәйдәшев, Г. Исхакый, Яшьләр урамнары буенча юлларны кардан чистарту; Куакбаш авылы К. Маркс, М. Җәлил, Х. Такташ, Г. Исхакый урамнарындагы юллардагы чокырны вак таш белән ремонтлау);
2) торак пунктның башка территорияләрен төзекләндерү (Куакбаш авылындагы балалар мәйданчыгын төзекләндерү (куакларны кисү, мәйданнарны планлаштыру, туфрак эшкәртү, комнан булган нигезнең түшәү һәм тигезләү катламнарын ясау);
3) янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (мотопомпа һәм янгын җиңсәсе сатып алу).

3. Әлеге карарны түбәндәге адрес буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә: Татарстан Республикасы, Лениногорск районы, Куакбаш авылы-К. Маркс ур., 15 йорт, Сходнево-Чертанлы авылы, Ирек ур., 5б йорт, Чүте авылы, Тынычлык ур., 8а йорт, авыл клубы бинасында, Лениногорск муниципаль

районының рәсми сайтында (http://leninogorsk.tatarstan.ru) «Авыл җирлекләре» бүлегендә һәм Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (https://pravo.tatarstan.ru/) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә бастырып чыгарырга.

Лениногорск муниципаль районы
«Куакбаш авыл җирлеге»
муниципаль берәмлеге башлыгы Р.Р.Әхмәтҗанова